Расланды
МБГБУ «Колбай Мораса урта гомуми белем мәктәбе” директоры
М.И.Валеев
Приказ № 42
1 сентябрь 2025 ел

Педагогик киңәшмәдә каралды
беркетмә №1
31 август 2025 ел

# Комплексы тематик эш планы

2025-2026 нчы уку елы

| Ай исеме | Атналар | Атна темасы | Максат | Йомгаклау чарасы |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | 1нче атна | “ Сөмбелә” | Алтын көзнең матур мизгелләре турында белемнәрен барлау. Җиләк –җимеш, яшелчәләрне, гөмбә төрләрен искә төшереп кабатлау.Игенче хезмәте, икмәкнең тырмыш чыганагы икәнен төшендерү. | “ Көзге байлык” күргәзмә |
| | 2 нче атна | Минем туган | Гаилә,авылыбыз,районыбыз,республикабыз турында белемнәрен киңәйтү,мактаулы,истзлекле урыннары турында мәгълүмат бирүне дәвам итү,туган якка мәхәббәт тәрбияләү. | С-рольле уен “Гаилә”не оештыру |
| | 3 нче атна | «Халыкара табиблар көне» | Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү.Аларны табиб хезмәте һәм аерым төрләре (лор, окулист, хирург) хезмәткәрләренең хезмәте белән таныштыру.Алар хезмәтенең мөһимлеге , әһәмиятлеге турында сөйләү.Хезмәт кешесенә хөрмәт, шәфкать һәм ихтирам тәрбия | медпунктка экскурсия. Рәсемнәр карау. Әңгәмә: «Табиб ничек эшли» |
| | 4 нче атна | Әни көне . | Әниләргә хөрмәт тәрбияләү.<br>Максат: Әни сүзе – иң бөек сүз. Әниләрне ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү, өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт белән карарга, ярдәм итәргә әзер булырга күнектнрү. | Әниләр көненә багышланган шигырь конкурсы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Кешенең тышкы кыяфәтенә карап, аның кәефен тоемларга, сүз һәм эш белән өлкәннәрнең күңелен күрә белергә өйрәтү. | |
| Ноябрь | 1нче атна | бердәмлеге көне » (День народного единства) | Бердәм Россиядә күп милләтле телләрне формалаштыру. Күп милләтле халыкларга хөрмәт тәрбияләү. | “Туган ил” шигырь конкурсы |
| | 2 нче атна | «Табигатьнең юмарт муллыгы» | Балаларның үсемлекләр, табигатьтә сезонлы үзгәрешләр турындагы күзаулларын киңәйтү. Урман, сулыклар, һава һәм туфракның кешегә тереклек дөньясы һәм үсемлекләргә йогынтысын аңлату. Табигать күренешләрен күзәтергә, кайбер закончалыклар һәм алар арасындагы үзара бәйләнеш турында нәтиҗә чыгарырга өйрәтү. Хезмәт кешеләренә хөрмәт һәм хезмәт итүгә теләк тәрбияләү. Балалрның яшелчәләр, җиләк-җимешләр, көзге кием-салымнар турында белешләрен арттыру. Көзге муллык турында шигырьләр өйрәнү. Балаларның фикерләү сәләтен арттыру. Әйләнә тирәгә кызыксыну тәрбияләү. | Әзер яшелчә сүрәтләрен (трафаретлар ярдәмендә) төшерү һәм әзер яшелчә муляжлары белән чагыштыру |
| | 3 нче атна | «Сәламләү һәм килешү көне » | Кешеләрнең үзара аралашу культурасы яшьтәшләренә крарата кайгыртучан, аларның кичерешләренә игътибарлы | Капма-каршы матур сүзләр әйтешү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | булырга, ярдәм күрсәтергә, үзенең һәм иптәшләренең уңышларына шатлана, уңышсызлыкка очраганда хәленә керергә өйрәтү. Үзара дусларча мөнәсәбәтләрне ныгыту. Яшьтәшләрнең кылган эшләренә мөнәсәбәтен бедерергә, үзе һәм иптәшләре кылган эшкә бәя бирергә, ихтирам тәрбияләүне формалаштыру. | |
| | 4 нче атна | “Әниләр көне” | :Әни сүзе – иң бөек сүз. Әниләрне ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү, өлкәннәр хезмәтенә хөрмәт белән карарга, ярдәм итәргә әзер булырга күнектнрү. Кешенең тышкы кыяфәтенә карап, аның кәефен тоемларга, сүз һәм эш белән өлкәннәрнең күңелен күрә белергә өйрәтү. | Әниләр көненә багышланган шигырь конкурсы |
| Декабрь | 1нче атна | “Шәфкатьлелек атнасы”. (Халыкара инвалидлар көне)<br>. | Балаларга сәламәтлегендә кимчелек булган кешеләрнең (инвалидларның) безнең кебек кеше икәнен, аларга тирә-юньдәге кешеләрнең аерым игътибарлыгы кирәклеге икәнлеген һәм ничек итеп аларга ярдәм итә алу турында аңлату | Открыткалар ясау |
| | 2 нче атна | «Кыш- кышкай» тәрбияләү. | Балаларны кыш фасылы белән таныштыру,табигатьнең нинди үзгәрешләр кичерүе, кошлар һәм җәнлекләрнең үзләрен бу вакытта ничек тотулары, ачлык һәм суыкны ничек уздырулары, сюжетлы | Кыш турында күргәзмәгә рәсем ясау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | рәсемнәр буенча хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү, кышкы кием-салымнар турында белемнәрен арттыру. Кыш турында шигырьләр өйрәнү, балаларның фикерләү сәләтләрен арттыру, әйләнә-тирәгә кызыксыну | |
| | 3 нче атна | «Кышкы уеннар» | Балаларны кышкы уен төрләренең бик күп төрле булулары турында таныштыру. Булачак олимпиада уеннары турында аңлату.Танып белгән һәм беленәчәк мәгълүматларга нигезләнеп, аларның сөйләмен, танып белү активлыгын үстерүне һәм шул ук вакытта шәхес формалаштыруны дәвам итү. | “Кышкы уеннар” темасына күргәзмә ясау |
| | 4 нче атна | «Исәнме, Яңа ел бәйрәме» | Балаларга Яңа ел бәйрәменең күңелле бәйрәм икәнен һәм ни өчен шулай дип аталуы турында сөйләп аңлату. Тирә-юндәге кешеләргә, туганнарга шатлык кына бүләк итәргә һәм бирелгән бүләкләрне рәхмәт әйтеп алырга кирәклеге турында фикер алышу. | бүләккә открыткалар ясау |
| Гыйнвар | 2 нче атна | «Хәрәкәттә – бәрәкәт» | Балаларда спорт төрләренә булган кызыксынуларын хуплау, хәрәкәт осталыклврын һә м күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү. Спорт уеннары элементлары, ярыш элементлары булган | “Күңелле стартлар” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | уеннарны ныгыту. Балаларда җитезлек, өлгерлек, чыдамлык, әхлакый ихтияри сыйфатлар-түземлек, ныклык, намуслык, оешканлык, спортны ярату хисе тәрбияләү. | |
| | 3 нче атна | «Әдәп төбе – матур гадәт» | Балаларда әдәпле сөйләм күнекмәләре булдыру. Ягымлы сүзләр исәбенә сүзлек байлыгын үстерү. Тирә-юньдәге кешеләргә үтенеч белән ягымлы мәрәҗәгать итә, күрсәткән ярдәмнәре өчен рәхмәт әйтә белүне ныгыту.Сөйләмдә халык авыз иҗатын файдалану күнекмәләрен камилләштерү. Әхлак сыйфатлары булдыруда туган телнең әһәмиятен үстерү. Һәр кылган яхшы гамәлгә рәхмәтле була белү, уңай бәя бирә белүне ныгыту. Әдәплелек кагыйдәләрен дөрес үти белү, әхлак сыйфатлары тәрбияләү. | Капма каршы тылсымлы сүзләр әйтешү |
| | 4 нче атна | «Сәламәт тәндә - сәламәт акыл» | Балаларда культура-гигиена күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, үзен һәрвакыт чиста, киемен һәм чәчән пөхтә йөртү гадәтен камилләштерү. Физик күнегүләрнең һәм спорт чараларының организмга ничек тәэсир итүе турында аңлату. Үзеңдә сәламәт булырга теләк уяту. Әдәби әсәрләр, җырлар аша сәламәтлеккә кайгыртучанлык хисе тәрбияләү. | Күңелле стартлар |
| Февраль | 1нче атна | ”Нәрсә яхшы, нәрсә начар” | Балаларда  яхшылык һәм начарлык турында күзаллаулар тудыру.Җәмәгать | “Яхшылык дөньясы” әңгәмә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | урыннарында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре(тыйнак булу, кычкырып сөйләшмәү, транспортта өлкәннәргә һәм үзеңнән кечкенәләргә урын бирү һ.б)белән таныштыру эшен дәвам итү.Кешеләргә карата хөрмәт һәм ярдәмчеллек тәрбияләү. | |
| | 2 нче атна | «Туган телнең матурлыгы» | Балаларга татар халкының әдип халык, моңлы,биюле, уен-көлкене яратучан җор халык икәнен аңлату.Туган илнең зурлыгына, байлыгына соклану, ул байлыкка кайгыртучанлык, сак караш тәрбияләү.Туган җир, туган ил, туган табигать, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү. | Татар халык киемнәрен трафареттан төшереп буяу күргәзмәсе |
| | 3 нче атна | “Безнең туган армия”. | Россия армиясе турында белемнәрен тирәнәйтү; войск төрләре турында элементар күзаллауларын булдыру; Бөек Ватан сугышында күрсәткән ил сакчыларының батырлыклары турында сөйләү; хикәянең эчтәлеген эмоциональ кабул итәргә күнектерү. | “Әтиләргә, бабайларга бүләк ясау” темасына күргәзмә ясау ” |
| | 4 нче атна | “Әниләр бәйрәме”. | Балаларга,әниләр көне турында мәгълүмат бирү, ни өчен бу көн әниләр бәйрәме дип аталуы турында сөйләп аңлату. Һәрвакыт әниләргә карата игътибарлы булуның кирәклеге турында фикер алышу. Үзләренең әниләре турында иптәшләренә | Әниләргә, әбиләргә бүләкләр әзерләү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | сөйләүләрен оештыру. Хатын- кызлар тормышына кызыксыну тәрбияләү. | |
| Март | 1нче атна | Әниләр бәйрәме” | Балаларга,әниләр көне турында мәгълүмат бирү, ни өчен бу көн әниләр бәйрәме дип аталуы турында сөйләп аңлату. Һәрвакыт әниләргә карата игътибарлы булуның кирәклеге турында фикер алышу. Үзләренең әниләре турында иптәшләренә сөйләүләрен оештыру. Хатын- кызлар тормышына кызыксыну тәрбияләү. | “Әниләр бәйрәме” |
| | 2 нче атна | “Халкыбызның гореф-гадәтләре” | Балаларны татар милли мәдәнияте белән таныштыруны дәвам итеп, аларда борынгы гореф-гадәтләргә ихтирам тәрбияләү. | |
| | 3 нче атна | :«Табигатьтә яз (Нәүрүз)» | Балаларны табигатьтәге үзгәрешләр белән таныштыру,табигать уянуын үсемлекләр, кошлар, хайваннар дөньясы аша күрсәтү,табигатьне ярату хисләре тәрбияләү. | саф һавада халык уеннарын уйнауны оештыру. |
| | 4 нче атна | Җир һәм су атнасы | Кеше яшәеше өчен кирәк булган су һәм җиргә сак караш тәрбияләү,тере һәм тере булаган табигать турында тулырак мәгълүмат бирү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Апрель | 1нче атна | “Юлда сак булу кагыйдәләре”. | юлда йөрү кагыйдәләрен өйрәтү; светофорның эшчәнлеге турында белемнәрен ныгыту; юл билгеләре һәм аларның кулланышы турында күзаллауларын киңәйтү; үзеңнең һәм кешеләрнең куркынычсызлыгы өчен җаваплылык тәрбияләү. | светофор янына сәяхәт. |
| | 2 нче атна | “Космонавт буласым килә”. | беренче косманавт Ю.А.Гагаринның биографиясе белән таныштыру; хәзерге заман һөнәрләре турында күзаллауларын киңәйтү; Россия космонавтларының хәзерге вакытта космоста эшләре турында сөйләү.<br>. | беренче космонавт һәм космос турында видеосюжет карау |
| | 3 нче атна | “Гжель”. | гжельдән ясалган предметлар тарихы турында күзаллауларын киңәйтү; гжель һәм скопин керамикасы белән таныштыру, аларның охшаш һәм охшамаган үзенчәлекләрен таный белергә өйрәтү. | гжель рәсемнәр конкурсы. |
| | 4 нче атна | “Җир шары- безнең уртак йортыбыз”. | “Җир шары- безнең уртак йортыбыз”дигән төшенчә белән таныштыруны дәвам итү; җир шарында күп илләр, төрле милләт халкы, яши дип сөйләү; барлык халыкка карата кызыксыну һәм хөрмәт хисе формалаштыру, аларның | “Яшәсәк тә без төрле җирдә”күңел ачу кичәсе. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | яшәү рәвешләренә басым ясап; культураның төрлелеген, бәйрәмнәрен күрсәтү. | |
| Май | 1нче атна | “Безнең Армия. Җиңү көне”. | Россия армиясе турында белемнәрен тирәнәйтү; сугышта һәлак булган сугышчыларга карата хөрмәтле булырга өйрәтү; һәйкәлләргә чәчәкләркуярга күнектерү; Туган илебезне яклаучыларга нинди бүләкләр бирүләре турында таныштыру. | Һәйкәл янына сәяхәт. |
| | 2 нче атна | “Телевизор безнең өйдә”. | хәзерге тормышта аерылгысыз өлеш булып торучы телевизор турында, телевидениеда эшләүчеләр турында таныштыру. | телевизор карау. |
| | 3 нче атна | “Тарих бишеге (Санкт-Петербург шәһәре)”. | Россия шәһәрләре турында күзаллауларын киңәйтү; Санкт-Петербург шәһәре һәм аның истәлекле урыннары белән таныштыру; үзләре күргәннәрне аңлатып сөйли белергә өйрәтү. | Санкт-Петербург шәһәре турында слайд карау. |
| | 4 нче атна | “Ел фасылы киемнәре”. | “Кием” дигән төшенчәне ныгыту; ел фасылына туры килгән киемне әйтә белергә, табышмаклар чишәргә өйрәтергә; художник-модельер эше белән таныштыру. | чыгарылыш кичәсе. |